Казан шәһәре Совет  районы “Күп профильле 181 нче мәктәп”

# «Күкнең җиденче катында»

№2 февраль , 2022 нче  ел




Бәйрәм бүген, олы бәйрәм,
Лачын егетләр бәйрәме!!!
Кулларында һәрберсенең,
Булсын чәчәк бәйләме!!!

Дан сезгә Ватан сакчылары,
Зур хөрмәткә сез лаек!!!
Барыбызда чын йөрәктән,
Без аларны котлаек!!!

Хәрбер егет горурланып,
Бәйрәм итә бу көндә!!!
Саулык теләп барысына,
Кала ул теләгендә!!!

Хөрмәт сезгә, һич онытылмас,
Сезнең данлы хезмәтләр!!!
Дөньялар да тыныч булсын,
Бәхеттә үтсен гомерләр!
(Рөстәм Кәримов)

Ватанны саклаучылар коне – кыюлык, намус һәм батырлык көне белән котлыйбыз сезне.

Бу көчле рухлылык, чын ир-егетләрнен батырлык, намус һәм абруй кебек сыйфатларга ия булуларын раслый торган бәйрәм. Ватанга һәм халыкка хезмәт иту – үз илен ихлас сөюче гражданнарнын һәрвакыт төп максаты булды һәм шулай булып калачак та.

Хәрби хезмәткәрләрнең бүгенге буыны һәм армия сафларын тулыландырырга әзерләнучеләр, илебезнең куркынычсызлыгы, туганнары хэм якыннарынын тормышы өчен җаваплылык хисен югалтмасыннар иде.

Сезгә һәм гаиләләрегезгә тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет, муллык, һәр эшегездә уңышлар телибез.

# Мәктәп яңалыклары



Һәр ел саен 14 нче февраль көнне “китап сөюче”ләр бер - берсенә китаплар бүләк итәләр. Бу матур гадәт безнең мәктәбебездә дә узды. Укучылар, укытучылар китаплар белән алмаштылар, китапларны бер- берсенә бүләк иттеләр.

### “Ватанны саклаучылар көне”нә багышланган класс маршировкалары

2-8, 10 сыйныф укучылары маршировкада катнашты. Командирның дөрес, аңлаешлы итеп команда бирүе, классның командаларны дөрес үтәүләре, атлаулары бәяләнде. Укучыларның әзерлекләре югары иде. Тышкы кыяфәтләре, үз-үзләрен тотышлары төгәл, дөрес булды.





### “Дус класс” исемендәге бәйге




Бу бәйгенең район туры узды. Мәктәбебезнең 6 нчы “ А” сыйныф укучылары, осталыклары, уңышлары, сәләтләре белән сөендерде. Район күләмендә 1 нче урынны яулап, шәһәр күләменә чыктылар.

Афәрин! Уңышлар Сезгә!




## Туган тел атналыгы

Бик кадерле, бик газиз, әни кебек якын булганга, аңа безнең халык ана теле, туган тел дип исем кушкан. Ана һәм туган тел! Мәңге аерылгысыз, изге төшенчәләр. Кешегә нәселенең, халкының асыл гадәт, сыйфатларын да иң әүвәл тел тәме, тел кодрәте ярдәмендә ана бирә. Туган тел – дөньяны танып белү, өйрәнү- төшенү өчен тылсымлы алтын ачкыч, могҗизалы асыл корал- үзара аралашу- аңлашу коралы ул. Адәм баласының иң изге, иң даһи хисләренең берсе - туган телгә гамьле, хөрмәте булу, төбәгең, шәҗәрәңне белүдер.

Февраль аенда мәктәбебездә телгә багышланган төрле чаралар, ачык дәресләр үткәрелде.

Исмәгыйлева Ләйсән Ринат кызы башлангыч сыйныф укучылары белән интеллектуаль уен; Сәләхова Ләйсән Ирековна 3 нче сыйныфта “Минем гаиләм” дигән темага ачык дәрес; Насыйбуллина Алсу Илдар кызы 5 нче сыйныфларда “Татар халкының милли киемнәре “ темасына класстан тыш чара; Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы 8 нче сыйныфларда сөйләм телен үстерү дәресе; Вәлиуллина Әлфинур Факил кызы югары сыйныфларда мастер-класс күрсәтте. Уздырылган чаралар мавыктыргыч, кызыклы һәм фәнни

**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
**Тираж** – 50 экз.
**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы
**Редколлегия әгъзалары:** Овезова Ләйлә, Сафина Камилла, Соколова София






